РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
СЕМЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СИМӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ **БАШКАРМА**
**КОМИТЕТЫ**

*423989, Р.Т. Муслюмовский район, с.Семяково, ул.Школьная д.8а*
Sem.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-33-16*
ИНН 1629003953, КПП 162901001, ОГРН 1061687005181, ОКАТО 92242865000

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
от 21 марта 2019 года № 17

**2019 елгы язгы ташу чорына Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау чаралары турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 7 маддәсе нигезендә 2019 елгы язгы ташу чорында халыкны, хуҗалык һәм торак объектларын, юлларны һәм күперләрне саклауны кисәтү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Симәк авыл җирлеге территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия төзү.
2. Симәк авыл җирлеге территориясендә 15 кешедән торган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен төзергә һәм 2019 елгы язгы ташу чорында Симәк авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау буенча чаралар планын расларга.
3. Симәк авыл җирлеге гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерүне һәм икътисад объектларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә тәкъдим итәргә:
   - Симәк авыл җирлегенең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгы, язгы ташуга каршы комиссия утырышларында икътисад объектларының куркынычсызлыгы, язгы ташу суларының авариясез үтүен тәэмин итү мәсьәләләрен карарга;
   - язгы ташу күренешләре аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләргә игътибар бирү һәм авария-торгызу эшләрен үткәрүгә җәлеп ителә торган көч һәм чаралар группировкасын ачыклау. Көч һәм чаралар турында мәгълүматлар җыю һәм гомумиләштерү, аларның гамәлләрен тикшереп тору;
   - елга һәм буаларда, саркофагларсыз үләт базлары янында су дәрәҗәсен тәүлек буе күзәтү өчен вакытлыча постлар оештырырга; - язгы ташуга каршы чаралар оештыруны тәэмин итү;
   - язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен халыкка җиткерүне тәэмин итәргә;
   - халыкны һәм территорияләрне язгы ташуның тискәре нәтиҗәләреннән саклау буенча чараларның үткәрелүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Симәк авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Ә. Садертдинов**

Мөслим муниципаль районы
Симәк авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
«21» март, 2019 ел,
17 нче санлы Карарына
1нче кушымта

**Симәк авыл җирлеге буенча**
**гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне тәэмин итү комиссиясе**

1. 1Садертдинов Рифас Абузарович
2. Сафина Раушания Хузагалиевна
3. Абдуллин Ленар Гатиятуллович
4. Гыйльметдинов Рамзи Агелтдинович
5. Муллашов Ленар Фангилович
6. Гусманов Динар Дамирович
7. Гусманов Даниль Дамирович
8. Валиев Ильшат Муллаянович
9. Гизетдинова Разиля Абугалиевна
10. Нуртдинова Рафида Гарайхановна
11. Салимов Зайнетдин Шарипович
12. Гыйльметдинова Зульфия Рафаеловна
13. Валиева Ландыш Рифовна
14. Садыкова Рамиля Ханифовна
15. Валиев Риф Галиевич – мезанизатор

**Симәк авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Ә. Садертдинов**